Татарстан Республикасы
Балык Бистәсемуниципаль районы
Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Советы

# КАРАР № 5

Казаклар Чаллысы авылы 15 декабрь, 2021 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Советының 2014 елның 13 октябрендәге “Җир салымы турында”гы 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Советының 2014 елның 13 октябрендәге “Җир салымы турында”гы 9 номерлы” карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Советының 2014 елның 16 ноябрендәге 10 номерлы, 2015 елның 28 маендагы 11 номерлы, 2017 елның 22 августындагы 11 номерлы, 2019 елның 14 июнедәге 8 номерлы, 2020 елның 4 февралендәге 2 номерлы, 2021 елның 7 декабрендәге 3 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пункттагы «беренче квартал беткәннән соң 15 майдан да соңга калмыйча, икенче квартал – 15 августтан да соңга калмыйча, өченче квартал-15 ноябрьдән дә соңга калмыйча. Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым суммасы узган салым чорыннан соң килүче елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә» сүзләрен алып ташларга.

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Казаклар Чаллысы авылы, Иванов урамы, 26 йорт, Иванай авылы, Калинин урамы,18 йорт; Бирдебәк авылы, Мәктәп урамы, 4 йорт;Үри Чаллысы авылы, Гаврилов урамы, 24 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.
5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Казаклар Чаллысы авыл җирлеге башлыгы И.С.Ананьев